РЕШЕНИЕ

16 июль 2023 ел                                                                                    № 1

«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 25 ноябрендәге 1 номерлы Вахит торак пункты җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 16 июлендэ түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 25 ноябрендәге 1 номерлы Вахит авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә Сез ризамы:

2.1. 5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- чишмәләргә йортлар (будкалар) урнаштыру, төзекләндерү һәм ремонтлау, чишмәгә керү юлларына, парковкаларга вак ташлар салу, асфальтлау, яктырту җайланмалары, смета документларын төзү»

2.2. 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - парк һәм аның тирәсендәге территорияне ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, арт-объектлар һәм МАФлар (кече архитектура формалары) сатып алу һәм урнаштыру, парк һәм ял зоналары өчен эскәмияләр ясау, сатып алу һәм урнаштыру, смета документларын төзү»

2.3. 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - канализация челтәрләрен ремонтлау, карап тоту, модернизацияләү, смета документларын төзү»

2.4. 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - физик культура һәм спортны үстерү, спорт инструкторларына түләү, спорт инвентаре сатып алу, спорт мәйданчыкларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, смета документларын төзү»

2.5. 13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - Вахит авылында тукталыш павильоны урнаштыру, ремонтлау, карап тоту, смета документларын төзү»

«РИЗА»                                        «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 627 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 320 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 312 кеше тавыш бирде;
«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 8 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит авылындагы халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» Янил торак пункты гражданнары җыенының 2022 елның 25 ноябрендәге 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме?

2.1. 5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«- чишмәләргә йортлар (будкалар) урнаштыру, төзекләндерү һәм ремонтлау, чишмәгә керү юлларына, парковкаларга вак ташлар салу, асфальтлау, яктырту җайланмалары, смета документларын төзү»

2.2. 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
« - парк һәм аның тирәсендәге территорияне ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, арт-объектлар һәм МАФлар (кече архитектура формалары) сатып алу һәм урнаштыру, парк һәм ял зоналары өчен эскәмияләр ясау, сатып алу һәм урнаштыру, смета документларын төзү»

2.3. 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
« - канализация челтәрләрен ремонтлау, карап тоту, модернизацияләү, смета документларын төзү»

2.4. 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
« - физик культура һәм спортны үстерү, спорт инструкторларына түләү, спорт инвентаре сатып алу, спорт мәйданчыкларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, смета документларын төзү»

2.5. 13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
« - Вахит авылында тукталыш павильоны урнаштыру, ремонтлау, карап тоту, смета документларын төзү»

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

ОГРН 1021607753310
ИНН 1623001893

Халык җыенында рәислек итүче
Янил авыл җирлеге башлыгы: И.Х.Корбанов